**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Старотатарско-Адамского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**

**423055 Республика Татарстан Аксубаевский район с. Старый Татарский Адам ул. Центральная дом 20**

Тел. (8-84344-4-35-84) ОГРН 1021605359610,
ОКПО 27839564, ИНН/КПП 1603000965/160301001
E-mail*: Stadam.Aks@tatar.ru*

---

Карар

№ 6 от 20.08.2025ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Башкарма комитетының "Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампалар туплану урыннары турында" 22.03.2021 № 4 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә (алга таба – кагыйдәләр) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге комитеты КАРАРы:
1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Башкарма комитетының "Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампалар туплану урыннары турында" 22.03.2021 № 4 карарын үзгәрешләр кертергә.:
1.1. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
"2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урынының (урыннарының) урнашуы турында мәгълүматны әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында (стойкаларында) урнаштыру юлы белән кулланучыларга җиткерергә. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге, адресы, ТР,Аксубай районы, Иске Татар Әдәмсуы авылы, Үзәк урамы, 20нчы йорт".

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: http://aksubayevo.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Э.М.Хөснуллина